КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 28 октябрь г.Казань № 874

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы үсеше өчен аеруча перспективалы һәм әһәмиятле өлкәләрдә Татарстан Республикасында яшь галимнәр һәм яшьләр фәнни коллективлары уздыра торган фәнни тикшеренүләргә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2024 ел, 26 октябрь, 926 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы үсеше өчен аеруча перспективалы һәм әһәмиятле өлкәләрдә Татарстан Республикасында яшь галимнәр һәм яшьләр фәнни коллективлары уздыра торган фәнни тикшеренүләргә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2024 ел, 26 октябрь, 926 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасын үстерү өчен иң перспективалы һәм әһәмиятле өлкәләрдә Татарстан Республикасында яшь галимнәр үткәрә торган фәнни тикшеренүләргә дәүләт ярдәме чаралары турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасының яшь галимнәренә ярдәм итү өчен республика фәнни премияләрен бирү тәртибе турында нигезләмәне расларга.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының яшь галимнәренә ярдәм итү өчен республика фәнни премияләрен бирү тәртибе турында нигезләмәдә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында яшь галимнәргә ярдәм итү өчен республика фәнни премияләрен бирү тәртибе турында нигезләмә»;

1 пунктта «Республикасының» сүзен «Республикасында» сүзенә алмаштырырга;

2 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«яшь галим - конкурска гариза бирү вакытына аның яше 35 яшьтән артмаган, Татарстан Республикасы үсеше өчен аеруча перспективалы һәм әһәмиятле өлкәләрдә фәнни тикшеренүләр алып баручы, яшь галимнең төп фәнни эш нәтиҗәләрен чагылдыра торган рецензияләнә торган фәнни журналларда һәм басмаларда басылып чыккан фәнни хезмәтләре булган, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан фәнни оешмаларда, югары белем бирү яисә өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф оешмаларында яисә милек рәвешенә һәм ведомствога бәйсез рәвештә башка оешмаларда аспирант, ординатор һәм (яисә) педагогик, фәнни һәм фәнни-техник хезмәткәрләр вазыйфаларында эшләүче Россия Федерациясе гражданы;»;

7 пунктта «12» саннарын «40» саннарына алмаштырырга, «44 мең сум» сүзләрен «138 200 сум» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Премияләр түбәндәге фәнни юнәлешләрнең берсе буенча фәнни эшләр өчен бирелә:

математика;

физика һәм астрономия;

химия, химик технология һәм нефть химиясе;

фәнгә нигезләнгән машина төзелеше: яңа төр технологик продуктлар;

мәгълүмат-коммуникация технологияләре, приборлар һәм мәгълүматны саклау;

геология, геофизика, геохимия һәм тау фәннәре;

табигатьтән рациональ файдалану, экология һәм әйләнә-тирә мохитне саклау;

география һәм атмосфера физикасы;

энергетика, энергия нәтиҗәлелеге һәм энергия ресурсларын саклау технологияләре;

архитектура һәм төзелеш;

медицина;

физиология, сәламәтлекне саклау;

авыл хуҗалыгы фәннәре һәм ветеринария;

биология һәм биотехнологияләр;

тарих һәм археология;

фәлсәфә, социология һәм хокук;

икътисад һәм идарә;

Татарстан Республикасы халыклары телләре һәм мәдәнияте;

педагогика һәм психология;

фәнни һәм гамәли әһәмияткә ия приборлар, методикалар, технологияләр һәм яңа фәнни-техник продукция эшләү яки булдыру.

Һәр фәнни юнәлеш буенча, әлеге Нигезләмәнең 24 пунктында каралган очраклардан тыш, ике премиядән артык бирелми.»;

9 пунктка түбәндәге эчтәлекле «ж» һәм «з» пунктчаларын өстәргә:

«ж) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшь галимнәргә дәүләт ярдәмен көчәйтү чаралары турында» 2003 ел, 19 май, 271 нче һәм «Татарстан Республикасы үсеше өчен аеруча перспективалы һәм әһәмиятле өлкәләрдә Татарстан Республикасында яшь галимнәр һәм яшьләр фәнни коллективлары уздыра торган фәнни тикшеренүләргә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2024 ел, 26 октябрь, 926 нчы карарлары нигезендә конкурс үткәрелгәнгә

кадәр алдагы өч ел дәвамында яшь галимнәргә ярдәм итү өчен республика фәнни премияләрен алмадылар;

з) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиеш булмаган йөкләмәләре юк.»;

12 пунктта:

беренче абзацта «бирелә» сүзен «конкурска түбәндәгеләрне үз эченә алган гариза бирелә» сүзләренә алмаштырырга;

татар текстында «а» пунктчасында «заявка» сүзен «гариза» сүзенә алмаштырырга;

«б» пунктчасында «педагогик, фәнни һәм (яисә) инженер-техник хезмәткәр вазыйфасында эшли» сүзләрен «аспирант, ординатор булып тора һәм (яисә) педагогик, фәнни һәм (яисә) фәнни-техник хезмәткәр вазыйфасында эшли» сүзләренә алмаштырырга;

«г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) салым түләүче (җыючы, иминият взнослары түләүче, салым агенты) салым, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, процентлар түләү бурычларын үтәве турында салым органы тарафыннан бирелгән белешмә;»;

түбәндәге эчтәлекле «ж» пунктчасын өстәргә:

«ж) тапшырылган документларның тасвирламасы.»;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Конкурс өчен гариза рус телендә бер нөсхәдә кәгазьдә әзерләнә. Конкурс өчен гариза тегелгән һәм битләп номерланган булырга тиеш. Конкурс өчен гаризага электрон тупланмада гариза күчермәсе теркәлә. Конкурс өчен гариза һәм аның электрон тупланмадагы күчермәсе «Татарстан Республикасында яшь галимнәрне хуплау өчен республика фәнни премияләре конкурсына» тамгасы белән конвертка салына һәм 420111, Казан шәһәре, Бауман урамы, 20 йорт, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе адресы буенча җибәрелә.»;

14 пунктта «конкурста катнашу өчен документлар» сүзләрен «конкурс өчен гаризалар» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктта «һәм аңа теркәлгән документлар конкурска тәкъдим ителә» сүзләрен «тәкъдим ителә» сүзенә алмаштырырга;

16 пунктта «әлеге Нигезләмәнең 12 пунктында күрсәтелгән документлар» сүзләрен «конкурс өчен гаризалар» сүзләренә алмаштырырга;

17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Конкурс өчен килгән гаризалар комиссия утырышында карала, ул конкурсны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән гаризалар кабул итү вакыты тәмамланганнан соң унбиш эш көненнән дә соңга калмыйча үткәрелә.»;

19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Конкурста катнашуга кертүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигезләр булып тора:

а) конкурска тәкъдим ителгән гаризаның әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

б) конкурсны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән кабул итү вакыты тәмамланганнан соң конкурс өчен гариза тәкъдим итү;

в) конкурс өчен гаризада булган дөрес булмаган мәгълүматлар ачыклану;

г) яшь галимнең әлеге Нигезләмәнең 9 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

д) яшь галимнең фәнни эшләре әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында күрсәтелгән фәнни юнәлешләргә туры килмәве;

20 пунктның беренче абзацында «өч» сүзен «биш» сүзенә алмаштырырга;

21 пунктта «10» саннарын «15» саннарына алмаштырырга;

23 пунктның беренче абзацында «һәм исемлектә беренче урынны алдылар» сүзләрен «, ләкин кимендә 20 балл, һәм исемлектә беренче һәм икенче урынны алдылар» сүзләренә алмаштырырга;

24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24. Әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында күрсәтелгән нинди дә булса фәнни юнәлешләр буенча конкурска бер генә гариза да бирелмәгән яисә кертелмәгән, яисә конкурс йомгаклары буенча конкурска бер генә гариза да 20 яки күбрәк балл җыймаган очракта комиссия башка фәнни юнәлешләр буенча конкурста катнашучылар исемлегендә гаризалары өченче һәм (яисә) дүртенче урынны алган һәм иң күп балл җыйган, әмма барлык фәнни юнәлешләр буенча өченче һәм (яисә) дүртенче урынны алган конкурска заявкалар арасында 20 баллдан да ким булмаган конкурста катнашучыларны конкурста җиңүчеләр итеп тану турында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президиумына үтенечнамә җибәрергә хокуклы.»;

25 пунктта:

беренче абзацта «өч» сүзен «биш» сүзенә алмаштырырга;

икенче абзацта «бер эш көне» сүзләрен «өч эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «бер эш көне» сүзләрен «ике эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

26 пунктта «конкурс җиңүчеләре» сүзләреннән соң «, шул исәптән әлеге Нигезләмәнең 24 пунктында күрсәтелгән очракларда,» сүзләрен өстәргә.

1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

2 нче кушымтаның 1 пунктының 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Фәнни эш тематикасының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы үсеше өчен аеруча перспективалы һәм әһәмиятле өлкәләрдә Татарстан Республикасында яшь галимнәр һәм яшьләр фәнни коллективлары уздыра торган фәнни тикшеренүләргә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2024 ел, 26 октябрь, 926 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында яшь галимнәргә ярдәм итү өчен республика фәнни премияләрен бирү тәртибе турында нигезләмәнең 8 пунктында каралган фәнни юнәлешләргә туры килүе (фәнни эшләрнең конкурсның тематик фәнни юнәлешләренә туры килүе, фәнни эш формулировкаларының төгәл булуы, аңлатма бирә торган документларның булуы бәяләнә)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасының яшь галимнәренә ярдәм итү өчен республика фәнни премияләрен бирү тәртибе турында нигезләмәнең 1 нче кушымтасы
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 28 октябрь, 874 нче
карары редакциясендә)

Форма

Татарстан Республикасында яшь галимнәргә ярдәм итү өчен республика фәнни премияләрен бирү өчен конкурска гариза

| | |
|---|---|
| 1. Гариза бирүче аспирант, ординатор һәм (яки) эшли торган оешма (тулы һәм кыскартылган исемен, юридик затның адресын күрсәтергә) | |
| 2. Оешма җитәкчесе: | |
| фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | |
| вазыйфасы | |
| эш телефоны | |
| 3. Гариза бирүче: | |
| фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | |
| туган көне | |
| вазыйфасы | |
| телефоны | |
| e-mail | |
| 4. Фәнни эш турында мәгълүмат: | |
| исеме | |
| юнәлеше* | |
| 5. Фәнни эшнең тасвирламасы (Татарстан Республикасы өчен перспектив фәнни өлкәләрне үстерү өчен эшнең әһәмияте һәм актуальлеге нигезләмәсе, аның төп бүлекләренең эчтәлегенең кыскача тасвирламасы, характеристикалары һ.б., аны башкару нәтиҗәсендә ирешелгән нәтиҗә) | |

Шуның белән конкурска гаризада тәкъдим ителгән барлык мәгълүмат дөрес һәм ышанычлы булып тора, һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе дәүләт фәнни бюджет учреждениесенә эш урынында һәм дәүләт һәм муниципаль хакимият

*ТТатарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы үсеше өчен аеруча перспективалы һәм әһәмиятле өлкәләрдә Татарстан Республикасында яшь галимнәр һәм яшьләр фәнни коллективлары уздыра торган фәнни тикшеренүләргә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2024 ел, 26 октябрь, 926 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында яшь галимнәргә ярдәм итү өчен республика фәнни премияләрен бирү тәртибе турында нигезләмәнең 8 пунктында күрсәтелгән.

органнарында тәкъдим ителгән мәгълүматларны ачыклау өчен мәгълүмат соратырга ризалык бирәм, шулай ук Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе дәүләт фәнни бюджет учреждениесе һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан конкурс үткәрү шартлары һәм тәртибен үтәүне тикшерүгә ризалык белдерәм.

Гариза биручe:

______________________________________________

(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

Заявка бирүченең имзасын раслыйм:

| ______________________ | ______________________ | ______________________ |
|---|---|---|
| (гариза бирүче аспирант, ординатор һәм (яки) эшли торган оешманың кадрлар бүлеге хезмәткәре яки башка вәкаләтле затның вазыйфасы) | (имза) | (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)) |

М.У. (булганда)

______________________